**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**«09» октябрь, 2017 ел №50**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 21 апрелендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 01 маендагы 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 05 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыйшавыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 статьяның 2 өлешендәге 11 абзацында «тиешле вазыйфаи төркемнәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«7. Аерыклы белгеч яисә магистр дипломы булган затлар өчен диплом бирелгән көннән алып өч ел эчендә муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен белгечлек буенча эш стажына - муниципаль хезмәт стажына кимендә ярты ел яисә белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнә.»;

1.2. 21 статьяда:

1) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ел саен төп түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә 30 календарь көн дәвамлылыгы белән бирелә.»;

2) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ел саен өстәмә түләүле яллар муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда һәм әлеге Нигезләмәдә каралган очракларда бирелә. Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәргә еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгы 40 календарь көннән арта алмый. Нормалаштырылмаган хезмәт

көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне дәвамлылыгы өч календарь көнгә тигез еллык өстәмә түләүле отпуск бирелә. Нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен еллык өстәмә түләүле отпуск, шулай ук федераль законда каралган башка очракларда бирелә торган еллык өстәмә түләүле отпусклар әлеге өлештә каралган еллык төп түләүле отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгыннан тыш бирелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы** **И.Р.Җиһаншин**